# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

**(V чакырылыш)**

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

# КАРАРЫ

«02» апрель 2026 ел № 7 Урыссу штб

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль закон, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалткан дип тану турында» 31.12.2025 № 1009 Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип таныргa:

- Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 23.10.2014 № 54 карары "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында;
- Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 20.07.2015 № 37 карары "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында;
- Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 21.08.2017 ел, № 25 карары «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны

һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау хакында».

- Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү турында һәм Татарстан Республикасы Ютазы район Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 25.07.2021 № 51 карары;

- Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.06.2022 елның 26 санлы карары "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм бу белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында";

- Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.06.2022 елның 23 санлы карары «Татарстан Республикасы Ютазы район Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы –
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин